ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики
Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ,
ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ, СЫЙФАТЫН
ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ
БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе)

# ПРИКАЗ

**22.08.2019** **№ 10-07/147**

Казан шәһәре

Кулланучыларның хокукларын яклау
темасын иң яхшы яктыртуга республика
конкурсын уздыру хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклауның комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасына кушымтаның 2.1 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1. Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын уздыру турында нигезләмә (кушымтада бирелә) (алга таба – Нигезләмә) расларга.
2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенә (Р.М.Арсланова) кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү эшен расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә оештырырга.
4. Боерыкны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге башлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары башлыкларына җиткерергә.
5. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Ф.Г.Хәммәтовка йөкләргә.

**Җитәкче** **Ж.Й.Әхмәтханов**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2019 елның 22 августындагы 10-07/147 номерлы боерыгы белән расланды

Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын уздыру турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклауның комплекслы системасын үстерү» дигән 6 нчы ярдәмче программасына кушымтаның 2.12 пункты (алга таба – Программа) нигезендә үткәрелә.

1.2. Конкурсны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге оештыра.

2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – массакүләм мәгълүмат чараларын (алга таба – ММЧ) кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрен киң яктыртуга җәлеп итү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрен пропагандалауга зур өлеш керткән журналистларның иҗади активлыгын бүләкләү;

ММЧда кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрен яктырту методларын һәм формаларын камилләштерү;

кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрендә республика гражданнарын агарту дәрәҗәсен күтәрү.

3. Конкурс номинацияләре

Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә, аларның һәркайсында җиңүче билгеләнә:

«Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктырту буенча басма ММЧда иң яхшы мәкалә»;

«Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы теле-, радиосюжет (яки теле-, радиотапшыру)»;

«Татарстан Республикасында гражданнарның кулланучылык белемен арттыру буенча иң яхшы ММЧ редакциясе»;

«Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы интернет-басма».

## 4. Гариза бирүчеләр һәм Конкурста катнашучылар

Конкурста массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, аерым авторлар, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы юридик затлар катнаша ала.

Конкурска гариза бирүчеләр – әлеге Нигезләмәнең 5.7 пункты нигезендә документлар пакетын тапшырган ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, шулай ук юридик затлар (алга таба – Мөрәҗәгать итүчеләр).

Конкурста катнашучылар – әлеге Нигезләмәнең 6.1-6.3 пунктларына ярашлы рәвештә конкурс эшләре Конкурста катнашу өчен кертелгән массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, аерым авторлар, юридик затлар (алга таба – Катнашучылар).

## 5. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм шартлары

5.1. Конкурс бер этапта 2019 елның 1 октябреннән 20 ноябренә кадәр үткәрелә.

Конкурс үткәрү турында мәгълүмат 2019 елның 20 сентябреннән соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://gosalcogol.tatar.ru) һәм Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы порталында (https://www.tatzpp.ru) урнаштырыла.

5.2. Әлеге Нигезләмәнең 5.7 пунктында күрсәтелгән документлар пакетын Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә тапшыру срогы – 2019 елның 1 октябреннән 20сенә кадәр (бу көнне дә кертеп).

Документлар пакеты түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 420107, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Һади Такташ ур., 94 йорт, кулга тапшырып, почта яисә электрон почта аша: konkurs.zpp@tatar.ru, «Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга конкурс» дигән тамга белән.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 277-94-99, 277-94-95.

5.3. Конкурска бер гариза бирелгән яки бер генә гариза да тапшырылмаган очракта, Конкурс үтмәгән дип таныла.

5.4. Конкурсны оештыручыларга әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән Конкурс номинацияләре нигезендә 2019 елда Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә оештырылган конкурс эшләре тәкъдим ителә.

5.5. Конкурска конкурс эшләренең түбәндәге төрләре кабул ителә:

MP4 форматында яки CD- яисә DVD-дискта һәм (яки) флеш-хәтер картасына яздырып алу өчен актив сылтама белән тапшырылган, озынлыгы 15 секундтан ким булмаган телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, телесюжетлар цикллары һәм башка телевизион эшләр);

MP4 форматында яки CD- яисә DVD-дискта һәм (яки) флеш-хәтер картасына яздырып алу өчен актив сылтама белән тапшырылган, озынлыгы 15 секундтан ким булмаган радиосюжетлар (программалар, махсус репортажлар,

радиосюжетлар цикллары);

басма, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка төрле басма, электрон ММЧ (газеталарда (журналларда, альманахларда) басылып чыккан, җитәкченең имзасы һәм юридик затның мөһере (булган очракта) белән йә физик затлар өчен автор имзасы белән таныкланган, кимендә 1500 билгедән торучы, төп нөсхәсендә һәм (яки) күчермәдә, һәм (яки) сканер аша чыгартылган вариантында тапшырылган мәкаләләр (мәкаләләр сериясе, махсус чыгарылышлар).

5.6. Конкурска тәкъдим ителгән эшләр рецензияләнми.

5.7. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр түбәндәге документлар пакетын тапшыра:

1) әлеге Нигезләмәнең 5.5 пунктына ярашлы форматта конкурс эше;

2) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына ярашлы формада катнашу өчен анкета-гариза (төп нөсхәсе, күчермәсе яки PDF-файл форматында сканер аша чыгартылган варианты);

3) юридик затлар буларак теркәлгән Татарстан Республикасы юридик затлары, ММЧ редакцияләре өчен түбәндәге документлар:

салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык (салым түләүченең идентификация номеры) (күчермә);

юридик затның дәүләт теркәве турында таныклыгы (төп дәүләт теркәү номеры) (күчермә);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләү турында боерык (күчермә);

гамәлгә кую документлары (күчермә);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

ММЧны теркәү турында таныклык (күчермә) яки теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә – ММЧ өчен;

4) физик зат-авторлар өчен:

паспорт яки аны алмаштыручы документ (2 нче, 2,3 нче битләренең һәм яшәү (теркәлү) урыны адресының күчермәсе);

салым түләүченең идентификацияләү номеры;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына ярашлы формада шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык;

5) юридик зат булып оешмаган ММЧ редакцияләре өчен:

ММЧны теркәү турында таныклык яки теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә (күчермә);

ММЧ редакциясе уставының яисә, «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 20 статьясы нигезендә, аны алмаштыручы шартнамә күчермәсе, әгәр ММЧ редакциясе 10 азрак кешедән торса;

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (ШЭ өчен);

вазыйфага баш мөхәррирне билгеләү турында боерык күчермәсе.

Әлеге пунктның 2-5 пунктчаларында күрсәтелгән документларны кәгазьдә яки электрон рәвештә PDF-файл форматында сканер аша чыгартылган вариантта тапшырыла.

5.8. Конкурска тапшырылган документлар пакеты Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан Мөрәҗәгать итүчедән алынган көннән соң бер эш көне эчендә теркәлә.

5.9. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һәм башкалар) Мөрәҗәгать итүчеләр һәм Катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль

түләнә.

5.10. Конкурска йомгак Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс эшләре кабул итүне тәмамлаган көннән башлап 30 календарь көне эчендә ясала һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары комиссия утырышы датасыннан соң ике эш көне эчендә кул куя.

5.11. Конкурска тапшырылган документлар Катнашучыларга фәкать алар таләбе белән, Катнашучыдан конкурс эшен кире кайтару турында таләп алынган көннән соң 20 календарь көне эчендә кайтарыла.

5.12. Конкурс эшләре Конкурска йомгак ясалганнан соң өч ел дәвамында саклана.

## 6. Конкурс эшләрен кертү критерийлары

6.1. Конкурс эшен Конкурста катнашуга кертү стадиясендә Оештыручылар тарафыннан Мөрәҗәгать итүчедән документлар алынган көннән башлап өч эш көне эчендә конкурс эшләрен әлеге Нигезләмәнең 5.4, 5.5, 5.7 пунктларында бәян ителгән таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләү нәтиҗәләре буенча Конкурска кертү яки кертүдән кире кагу турында карар кабул ителә.

6.2. Конкурс эшенең әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве Конкурста катнашудан кире кагу өчен нигез булып тора. Мөрәҗәгать итүчеләргә конкурс эшен Конкурста катнашуга кертүдән кире кагу турында мондый карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә хәбәр ителә.

6.3. Конкурска кертелмәгән конкурс эшләре, Конкурска документлар тапшыру өчен билгеләнгән вакытта җитешсезлекләре бетерелгәннән соң, яңадан Конкурска тәкъдим ителергә мөмкин.

## 7. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

Конкурска кертелгән конкурс эшләрен бәяләгәндә түбәндәге критерийлар кулланыла:

Конкурс тематикасын чагылдыра торган эчтәлек (0-10 балл);

сурәтләү ысулларын куллану (0-10 балл);

мәкаләләрнең һәм сюжетларның Татарстан Республикасы халкы өчен тәрбияви һәм иҗтимагый әһәмияте (0-10 балл);

экспертлар белән эшләү һәм интерактивтан файдалану (0-10 балл);

идеясенең һәм материалны бирү ысулларының оригинальлеге (0-10 балл);

Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау турында материаллар сериясе (ике һәм аннан күбрәк) булу (0-10 балл).

## 8. Конкурс комиссиясе

8.1. Килгән конкурс эшләренә бәя бирү максатында конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Комиссиянең персональ составы конкурсны оештыручылар һәм ведомство буйсынуындагы оешмалардан 6 вәкил катнашында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана.

8.2. Комиссия үз эшен түләүсез нигездә башкара.

8.3. Комиссиянең эшенә рәис җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, Конкурс комиссиясе рәисе вазыйфалары Конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

8.4. Комиссия эше утырышлар рәвешендә башкарыла. Утырыш, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

8.5. Комиссия рәисе Комиссия утырышларын үткәрү урынын, датасын һәм вакытын билгели, Комиссия утырышларында рәислек итә һәм Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү мәсьәләләре буенча Комиссия сәркатибенә йөкләмәләр бирә.

8.6. Комиссия сәркатибе түбәндәге функцияләрне башкара:

конкурс эшләрен әлеге Нигезләмәнең 5.7 пунктында каралган документлар пакеты белән бергә кабул итә һәм терки һәм аларны саклауны оештыра;

конкурс эшләрен бәяләү өчен Комиссия әгъзаларына җибәрә;

Комиссиянең утырышын оештыра, документларны әзерли һәм беркетмә рәсмиләштерә.

Комиссия сәркатибе комиссия әгъзалары составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

8.7. Комиссия әгъзалары әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә билгеләнгән конкурс эшләрен бәяләү критерийлары нигезендә тәкъдим ителгән эшләрне бәяли. Һәр критерий буенча баллар саны 10 баллы шкала буенча билгеләнә (0-10).

8.8. Конкурска йомгак ясаганда түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) дүрт төп номинация буенча җиңүчеләр һәм дүрт өстәмә номинация буенча призерлар билгеләү турында;

б) номинацияләрнең берсе буенча да яки берничә номинация буенча «җиңүче» исемен бирмәү һәм өстәмә номинацияләр буенча призерларны билгеләү турында, әгәр тапшырылган эшләрнең берсе дә билгеләнеп үтелергә тиешле дип танылмаса яки аларның берсе дә әлеге Нигезләмәдә бәян ителгән таләпләргә җавап бирмәсә;

в) конкурсны узмаган дип тану турында.

8.9. Номинацияләрнең берәрсенә бер генә гариза бирелгәндә яки бер генә гариза да бирелмәгән очракта, яисә конкурс комиссиясе тарафыннан нинди дә булса номинация буенча «җиңүче» исемен бирмәү турында карар кабул ителгәндә, әлеге номинация буенча конкурс узмаган дип танныла һәм әлеге номинация буенча бүләккә бүлеп бирелгән акча тигез өлешләрдә башка номинацияләрдә билгеләнгән җиңүчеләргә бүленә.

8.10. Иң күп балл җыйган катнашучы җиңүче дип таныла. Номинациядә баллар тигез булганда призлы урын ике яки берничә катнашучыга бирелә. Шул ук вакытта тиешле призлы урын өчен каралган акчалар җиңүчеләр арасында тигез өлешләрдә бүленә.

8.11. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ачык рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында (http://gosalcogol.tatar.ru) урнаштырыла Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы порталында (http://tatzpp.ru) утырыш беркетмәсенә кул куелганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

8.12. Конкурста катнашучы Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, ул комиссиягә апелляция бирергә хокуклы.

Апелляция язмача рәвештә ирекле формада Комиссия рәисе исеменә Конкурс нәтиҗәләре басылып чыкканнан соң өч эш көне эчендә бирелә һәм Комиссия әгъзаларына җибәрелә.

Комиссия әгъзалары апелляцияләр килү чоры тәмамланган көннән соңгы дүрт эш көне эчендә аларны карап тикшерә һәм коллегиаль рәвештә фикер алыша. Карар ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш туплау нигезендә кабул ителә һәм Комиссиянең катнашкан әгъзалары күпчелекне тәшкил иткәндә, легитимлы булып танsocket. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәл итүле була. Комиссия сәркатибе Комиссия карары нигезендә беркетмә рәсмиләштерә. Беркетмәдә Комиссиянең һәр әгъзасының фикере һәм гомуми нәтиҗә күрсәтелә:

апелляцияне канәгатьләндермәү һәм бастырып чыгарылган нәтиҗәләрне саклау турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

Беркетмәгә Комиссия рәисе, рәис урынбасары, Комиссия сәркатибе һәм әгъзалары кул куя.

Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия карары иң соңгысы була, ул яңадан каралмый һәм суд тәртибендә шикаять кылынырга мөмкин.

## 9. Финанслау

9.1. Конкурс уздыру чараларын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

9.2. Конкурсның гомуми приз фонды 100,0 мең сум тәшкил итә.

9.3. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм түбәндәге акчалата призлар белән бүләкләнә (салым түләүләрен исәпкә алып):

| Номинацияләр | Бүләк-ләнүче-ләр саны | Суммасы, мең сум |
|---|---|---|
| «Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктырту буенча басма ММЧда иң яхшы мәкалә» | 1 | 20 |
| «Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы теле-, радиосюжет (яки теле-, радиотапшыру)» | 1 | 20 |
| «Татарстан Республикасында гражданнарның кулланучылык белемен арттыру буенча иң яхшы ММЧ редакциясе» | 1 | 20 |

| | | |
|---|---|---|
| «Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы интернет-басма» | 1 | 20 |

9.4. Конкурста җиңүче булмаган, әмма югары нәтиҗәләр күрсәткән (җиңүче балларының 80 һәм аннан да күбрәк проценты) катнашучылар өстәмә номинацияләрдә грамоталар һәм кызыксындыру призлары белән бүләкләнә:

«Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктыртуда ныклык һәм үҗәтлек өчен»;

«Көчле әйтелгән!»;

«Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктыртуда активлык өчен»;

«Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау темасын яктыртуда оригинальлек өчен».

9.5. Конкурсның приз фондын бүлү һәм Конкурска документлар тапшырганда анкета-гаризада күрсәтелгән кредит оешмасындагы счетка акча күчерү Конкурс комиссиясе карары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурска йомгак ясалганнан соң 15 календарь көне эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 10. Махсус шартлар

Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен закон нигезендә Конкурс эшләрен тәкъдим иткән Мөрәҗәгать итүчеләр һәм Катнашучылар җаваплы була.

Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

*РӘВЕШЕ*

Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика конкурсында катнашу өчен
**анкета-гариза**

Катнашучының исеме_______________________________________________
(оешманың исеме, катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Элемтә өчен телефон: ______________________________________________
e-mail____________________________________________________________
Эшчәнлекне гамәлгә ашыру адресы _____________________________________
_____________________________________________________________________

Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика конкурсында түбәндәге номинацияләрдә катнашуым турында белдерәм

_____________________________________________________________________
(күрсәтергә кирәк):
_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Конкурс нәтиҗәләре буенча тапшырылган акчаларны күчерү өчен Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет реквизитлары:
_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________
(Юридик затлар өчен: Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның имзасы, оешманың мөһере (булган очракта); физик затлар өчен: Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), имза)

«___»_____________ ел.                    _________________________
Катнашучының имзасы

Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык
(физик затлар тарафыннан тутырыла)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга (аларны миннән һәм/яки теләсә кайсы өченче затлардан алуны да кертеп) риза, түбәндәге күләмдә:

| | |
|---|---|
| Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге | (фамилия, исем, ата исеме, җенес, туу датасы һәм урыны, гражданлык, шәхесне раслый торган документ реквизитлары (документ төре, аның сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән мобиль), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет турында мәгълүматлар) |

_______________________________________________

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), имза)

______________

(дата)